# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**9 декабрь 2023 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 9 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены  нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

"Сез 2024 елда Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1000 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 500 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары, су өчен контейнер сатып алу);

- Бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру (чараларны уздыру өчен аппаратура сатып алу);

- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (балалар өчен уен аттракционнары сатып алу, МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (ботак турагыч, чапкыч), Бүләк авылы мәдәният йортын коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу, урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу)?"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 164 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 92.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА»  позициясе өчен  92,  «КАРШЫ»   позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

"Сез 2024 елда Сарлы авыл җирлеге Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында

катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1000 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 500 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары, су өчен контейнер сатып алу);

- Бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру (чараларны уздыру өчен аппаратура сатып алу);

- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (балалар өчен уен аттракционнары сатып алу, МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (ботак турагыч, чапкыч), Бүләк авылы мәдәният йортын коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу, урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу)?".

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хаҗиев